**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2315**
**19.05.2020**

Башкарма комитетның аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 266.1, 269.2 статьялары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 25 апрелендәге 2305 номерлы карары (Башкарма комитетның 2019 елның 16 маендагы 2519 номерлы карары редакциясендә) белән расланган эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 38 пунктның алтынчы абзацында «15» саныннан соң «эш» сүзен өстәргә;

2) 41 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчмә тикшерүне үткәрү туктатылган вакытта, аның дәвамлылыгы 30 эш көненнән артмаган срокка өзелә.».

2. Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3843 номерлы карары (Башкарма комитетның 2019 елның 19 августындагы 4266 номерлы карары редакциясендә) белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентка, 17 пунктның 5 пунктчасына «каршы тора алмаслык хәлләр чорына» сүзләреннән соң «30 эш көненнән артык түгел» сүзләрен өстәп, үзгәрешләр кертергә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                Ф.Ш. Салахов